
# ХӘСӘН ТУФАН

*(1900—1981)*



ТАТАР СОВЕТ ПОЭЗИЯСЕНЕҢ КЛАССИК ШАГЫЙРЕ ХӘСӘН ФӘХРИ УЛЫ ТУФАН 1900 ЕЛНЫҢ 27 НОЯБРЕНДӘ (ЯҢА СТИЛЬ БЕЛӘН —9 ДЕКАБРЬДӘ) ЭЛЕККЕ КАЗАН ГУБЕРНАСЫНЫҢ ЧИСТАЙ ӨЯЗЕ АКСУБАЙ ВОЛОСТЕ (ХӘЗЕРГЕ ТАТАРСТАННЫҢ АКСУБАЙ РАЙОНЫ) ИСКЕ КАРМӘТ АВЫЛЫНДА УРТА ХӘЛЛЕ КРЕСТЬЯН ГАИЛӘСЕНДӘ СИГЕЗЕНЧЕ БАЛА БУЛЫП ДӨНЬЯГА КИЛӘ. БУЛАЧАК ШАГЫЙРЬНЕҢ ӘТИСЕ ФӘХРИ АБЗЫЙ ИГЕН ИГҮДӘН ТЫШ, СӘГАТЬ ТӨЗӘТҮ, ПЫЯЛА КУЮ, ТИМЕРЧЕЛЕК КЕБЕК ЭШЛӘР БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНГӘН ҺӘМ БУ ҺӨНӘРЛӘРГӘ БАЛАЛАРЫН ДА ӨЙРӘТКӘН.

ХӘСӘН УКЫРГА-ЯЗАРГА ӘТИСЕННӘН ҺӘМ ҮЗЛЕГЕННӘН ӨЙРӘНӘ, Ә 1905 ЕЛГЫ РЕВОЛЮЦИЯДӘН СОҢ КАРМӘТТӘ МӘКТӘП АЧЫЛГАЧ, ШУНДА ЙӨРЕП УКЫЙ БАШЛЫЙ. 1914 ЕЛНЫҢ ЯЗЫНДА УЛ ТОБОЛ ГУБЕРНАСЫНЫҢ АХМАН АВЫЛЫНДА ЯҢА ҖИР АЛЫП УРНАШКАН АБЫЙЛАРЫ ЯНЫНА КИТӘ ҺӘМ ҖӘЕН АЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ БАКЫР КОЛЧЕДАНЫ РУДНИГЫНДА ЭШЛИ. ШУЛ ЕЛНЫҢ КӨЗЕНДӘ АБЫЙЛАРЫ АНЫ УФАГА «ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕНӘ УКЫРГА ҖИБӘРӘЛӘР. ҮЗ ЧОРЫНЫҢ АЛДЫНГЫ УКУ ЙОРТЛАРЫННАН САНАЛГАН БУ МӘДРӘСӘ Х. ТУФАННЫҢ БЕЛЕМ ДАИРӘСЕН КИҢӘЙТҮГӘ ҺӘМ ӘДӘБИ ИҖАТ ЭШЕНӘ ТАРТЫЛУЫНА УҢАЙ ЙОГЫНТЫ ЯСЫЙ. ШУНДА УЛ Г. ИБРАҺИМОВТАН ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ ТЫҢЛЫЙ, ШУЛ УК МӘДРӘСӘНЕҢ ШӘКЕРТЕ Ш. БАБИЧ ОЕШТЫРГАН ТҮГӘРӘККӘ ЙӨРЕП, ШИГЫРЬ СЕРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘНӘ, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘРДӘ С. РӘМИЕВ, М. ГАФУРИ, С. СҮНЧӘЛӘЙ КЕБЕК ШАГЫЙРЬЛӘРНЕҢ ЧЫГЫШЛАРЫН ИШЕТӘ. ҖӘЙГЕ КАНИКУЛ ВАКЫТЛАРЫНДА ЯШҮСМЕР ЕГЕТ, УКУЫН ДӘВАМ ИТӘРГӘ АКЧА ЮНӘТҮ ӨЧЕН, УРАЛ РУДНИКЛАРЫНДА ШАХТЕР, СӘГАТЬ ТӨЗӘТҮЧЕ, ЛЫСЬВА МЕТАЛЛУРГИЯ ЗАВОДЫНДА ТОКАРЬ БУЛЫП ЭШЛИ.

Х. ТУФАННЫҢ ИСЕМЕ МАТБУГАТТА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР 1924 ЕЛДА КҮРЕНӘ. ШУЛ ЕЛНЫ «ОКТЯБРЬ БАЛАСЫ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫ БИТЛӘРЕНДӘ АНЫҢ БЕРНИЧӘ ШИГЫРЕ БАСЫЛЫП ЧЫГА.ШУННАН СОҢ Х.ТУФАН  ТАТАР ШИГРЫЯТЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ШАГЫЙРЕ БУЛЫП ТАНЫЛА. СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫН ҮСТЕРҮДӘГЕ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ӨЧЕН ХӘСӘН ТУФАН ИКЕ ТАПКЫР (1970, 1980) ХЕЗМӘТ КЫЗЫЛ БАЙРАГЫ ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНДЕ, Ә «САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР» (КАЗАН, 1964) КИТАБЫ ӨЧЕН АҢА 1966 ЕЛДА ТАТАРСТАН АССРНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ БИРЕЛДЕ.

ХӘСӘН ТУФАН 1981 ЕЛНЫҢ 10 ИЮНЕНДӘ КАЗАНДА ВАФАТ БУЛДЫ.

# Хәсән Туфанның тоткынлыкта булуы

1940 - 56 елларда Хәсән ага тоткынлыкта була. Газап, кайгы- хәсрәт, үлем белән күзгә - күз очрашу чоры бу. Язмыш аны сындырып сыный... Ләкин шагыйрь иманына, халкына, иленә тугры кала.

1937 нче елда "Ант" поэмасы өчен Хәсән аганы Язучылар Союзыннан чыгаралар. Әсәрләре басылмый, китаплары тоткарлана. Көн саен, төн саен кулга алуларын көтеп яши ул.

1942 нче елның 7 нче мартында суд була. Аны үлем җәзасына хөкем итәләр. Шагыйрь ялгызы бер камерада үлем көтеп ята. Язмышы көтелмәгән борылыш ясый. Үлем карары 10 елга каты режимлы колония белән алыштырыла. Алга таба шагыйрьнең тормышы тагын да авырлаша. Ул иң авыр эшкә- урман кисәргә билгеләнә. Ашау ягы начарая, ачлыктан аяк-куллары шешенә.

Х. Туфан колониядә үз срогын тулысынча тутыра. Коточкыч арый, йончый. Физик яктан да, рухи яктан да Хәсән абый түземсезлек белән иреккә чыгу көннәрен көтә. Әмма бер сүз дә аңлатып тормыйча аны, Себергә мәңгелек сөргенгә җибәрәләр.

Х. Туфанның тоткынлык дәвере 16 елга сузыла. Сталин үлеп, аның сәясәтендәге җитди хаталары ачылганнан соң гына, шагыйрьгә иреккә чыгарга мөмкинлек туа. 1956 нчы елның җәендә ул Казанга кайтып төшә.


Ул өенә кайтканда аның улы да, хатыны да үлгән була инде, тик кызы гына һәм язучы дуслары гына каршы ала.


# ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ИҖАТЫ

**Хәсән Туфанның һәр шигыре матур, эчтәлекле.**

**Хәсән ага калдырган якты шигърият**

**безне дә аклыкка, пакьлеккә дәшә сыман. Әйдәгез,Хәсән Туфанның берничә шигыре белән дә танышып китик.**





РОМАШКАЛАР
РОМАШКАЛАР ТИРБӘЛӘ ҖИЛДӘ
БЕР КҮРЕНЕП, ТАГЫН КҮМЕЛЕП,
ЙӨГЕРӘ-ЙӨГЕРӘ ШАЯН НӘНИЛӘР
КЫРДА КАЧЫШ УЙНАГАН КЕБЕК.
РОМАШКАЛАР ҮСКӘН ДАЛАДА
ИСКӘ ТӨШТЕ БЕРГӘ ЧАКЛАРЫМ;
КӨТӘ МИКӘН, САГЫНА МИКӘН, ДИП,
КАНАТЛАРЫН ЙОЛКАМ АЛАРНЫҢ.
ЮК, РОМАШКА,
МИНЕМ ЙӨРӘКНЕҢ ЯНУЛАРЫН БАСА АЛМЫЙСЫҢ,
КӨТӘ ӘЛЕ, САГЫНА ҺАМАН, ДИП,
АЛДЫЙСЫҢ ИЧ МИНЕ, АЛДЫЙСЫҢ!
ЮК, ЫШАНМЫЙМ РОМАШКАЛАРГА,
АЛДАША ИЧ АЛАР, АЛДАША:
АНЫҢ КАБЕРЕ ӨСТЕНДӘ ИНДЕ
РЕЗЕДАЛАР ҮСӘ ЛӘБАСА...

# АК КАЕН



Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр,
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавына асып киттеләр.

Асучылар киткәч, сорый каен:
— Авыртмыймы муеның,
Хәйбулла?
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла.

Билбау кыса, каен,
сулышкайны,
Бушатсана шушы билбауны!
— Бушатыр да идем
билбавыңны,
Мин каенда андый кул бармы?

— Бөгелсәнә, каен, иелсәнә,
Аякларым җиргә тимәсме?
— Бөгелер идем, буем каты
минем,
Үтәр хәл юк синең киңәшне.

— Сәлам тапшыр, каен, — диде
егет,
Тынып калды шунда аннары...
Бер эндәште каен, өч эндәште,
Бүтән бер сүз ишетә алмады.

Яфраклары коела ак каенның,
Яфраклары коела яшь кебек.
Әле булса тирбәләдер төсле
Шул каенга аскан яшь егет.

Әйтсәгез лә шушы ак каенга:
— Елама син, каен, аппагым,
Киң кырларда үзе генә түгел,
Эзе дә юк инде ятларның.





Әгәр сөя калсаң.
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй... бары тик
Миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне...


Юлыктым мин, Лулу, бер чәчәккә,
Көтмәгәндә, уйламаганда.
Нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга...

Тормышымның синнән
соңгысында
Тапканым юк иде һичкемне.
Нишләргә соң? Бир бер киңәш
миңаа
Ул һәр яктан синең шикелле.

"Нишләргә соң?" — дигән сорау
белән
Киләм синең рәсемең каршына...
Үзең булсаң әгәр, мондый уйлар
Килер идемени башыма?!

# ӘЙТКӘН ИДЕҢ...

# Кайсыгызның кулы җылы?



ДӨНЬЯ МИНЕ
ҮЗГӘРТТЕ:
ЕЛАМАСКА ӨЙРӘТТЕ.
КҮЛМӘК ҖИҢЕН ЕРТАСЫМЫ? —
БӘЙЛИСЕ БАР
ЙӨРӘКНЕ.
СУГЫШЛАРДАН ЗАМАНА
ТУКТАП ТОРГАН АРАДА,
ЯРАЛАРНЫ ЯМАШТЫРЫП
ЯТА ИДЕМ
ДАЛАДА:
— КАЙТ!.. — ДИП ХАТЛАР
КИЛДЕЛӘР...
ЮЛЛАР... ОЗЫН ИДЕЛӘР...
КАЙТТЫМ.
— БУСЫ АЛКАЛАРЫ,
БУСЫ — КАБЕРЕ... — ДИДЕЛӘР.
ӘГӘР ТАГЫН КИЛСӘЛӘР,
— САУ! — ДИП ХӘБӘР БИРСӘЛӘР,
ВУЛКАННАРГА КЕРЕР ИДЕМ,
ШУНДАДЫР УЛ... ДИСӘЛӘР.
БИРДЕ ДӨНЬЯ КИРӘКНЕ,
ЕЛАМАСКА ӨЙРӘТТЕ...
КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?
— БӘЙЛИСЕ БАР ЙӨРӘКНЕ...

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына.
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла.

Нәрсә әйтсен: берни белми ул,
Хәбәре юк минең йөрәктән.
Мине бары чылатып үтте
Кукурузлар белән беррәттән...
Нәрсә әйтсен: берни белми ул.

Агыла да болыт агыла
Таулар аша Казан ягына.
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...



# АГЫЛА ДА БОЛЫТ АГЫЛА...

**Без, Хәсән Туфанның берничә шигырләрен карап үттек.**

**Нинди олы йөрәкле шагыйрь булган бу –Хәсән Туфан.**

**Аның “Ромашкалар” шигыре, укучыга бигрәктә дулкынлы хисләр китерә,моңландыра һәм уйландыра.Тагын “Агыла да болыт агыла...” шигыренә игътибар итегез.Хәсән Туфан,күрәсең,туган җирен,туган йортын сагына,болытларга карап моңлана,уйлана кебек.Шул болытларга Хәсән аганың туганнарына җиткерер хәбәрләрен әйтәсе килә булыр да,юк шул, болытлар телсез.Алар Хәсән аганың кичерешләрен,сагынуларын аңламый инде.**

Хәсән Туфанның музей-йорты Аксубай районы Иске Карәмәт авылында урнашкан.





БУ МУЗЕЙ ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ҮТКӘН ТОРМЫШЫ ТУРЫНДА СӨЙЛИ.АНДА БИК КҮП ТӨРЛЕ ИҖАТЫ ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАЛАР САКЛАНГАН.
ХӘСӘН АГАНЫҢ ҮЗ ӘЙБЕРЛӘРЕННӘН: КҮЛМӘГЕ (ХӘСӘН ТУФАН АНЫ ҮЗЕ ТЕККӘН),ХАТЫНЫ ЛУИЗА ХАНЫМНЫҢ ДОКУМЕНТЛАРЫ,ХӘЗЕРГЕ КӨННӘРГӘ КАДӘР ДӘ ЭШЛӘҮЧЕ МЕХАНИК-СӘГАТЕ, 30 НЧЫ ЕЛЛАРДА БАСЫЛГАН БЕРЕНЧЕ КИТАБЫ,КИТАП ШКАФЫ,КӨЗГЕ,ЧЕМОДАН,САМОВАР, ЧӘЙНЕК ҺӘМ БАШКА, САНАП БЕТЕРГЕСЕЗ КҮП ӘЙБЕРЛӘР.

## ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ЭШ ӨСТӘЛЕ





# ХӘСӘН ТУФАННЫҢ МУЗЕЙ-ЙОРТ ЭЧЕ

# Хәсән аганың киемнәре












# ХӘСӘН ТУФАН ИҖАТЫ БЕЛӘН БИК КҮП КЕШЕ КЫЗЫКСЫНА.ЧӨНКИ,МУЗЕЙ-ЙОРТНЫҢ БУСАГАЛАРЫННАН  БЕР ЕЛДА 3100 КЕШЕ  ҮТЕП КЕРӘ.







# ХӘСӘН ТУФАННЫҢ СӨЕКЛЕ ХАТЫНЫ, АРТИСТКА ЛУИЗА САЛИГАСКӘРОВА

# ХӘСӘН ТУФАН ПОРТРЕТЫ. РӘШИТ ИМАШЕВ






# ХӘСӘН АГАНЫҢ КИТАПЛАРЫ



















**ОНЫТМАБЫЗ СИНЕ, ХӘСӘН АГА, ШИГЫРЬЛӘРЕҢ ЯҢГЫРЫЙ КҮҢЕЛДӘ. БАТЫРЛЫГЫҢ БЕЗГӘ ҮРНӘК СИНЕҢ – ОНЫТЫЛМАССЫҢ ГОМЕР-ГОМЕРГӘ!**



БАШКАРДЫ: 5 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫСЫ ГАРИФУЛЛИНА ЧУЛПАН ИЛШАТ КЫЗЫ ҖИТӘКЧЕСЕ: САДРИЕВА ЭНҖЕ РӨСТӘМ КЫЗЫ